СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЗАЙ-КАРАТАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЗӘЙ-КАРАТАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.09.2026 №21

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат вәкаләтләре сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының хокуклы составтагы беренче утырышын уздырган көннән туктатыла..».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зәй-Каратай авылы, Совет урамы 99 йорт, Узбәк авылы Луговая урамы 2 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стенында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

«Зәй-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе М.И.Идиятова